## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИБӘХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**КАРАР**

**Утызынчы утырыш дүртенче чакырылыш**

**21сентябрь 2023ел № 83 Кече Кибәхуҗа ав.**

Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге советының 2015 елның 16 июнь №114 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«13» сентябрь 2023 елгы Исорог-20920037-589-23/20920037 номерлы Теләче районы прокуратурасының протестын карап чыгып, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге советының 2015 елның 16 июнь №114 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында» карарына (22.04.2016 ел №29, 19.09.2018ел № 98, 18.11.2021 ел № 32 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау регламентының 7.4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.4.2. Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Башлыгы (Раисе) мөрәҗәгатьләрен карау буенча йөкләмәләрне үтәү аерым контрольгә куела, аларны карау срогы 15 көнгә кадәр дәвам итә.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Теләче муниципаль районы
Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башлыгы И.Г.Заһидуллин